ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
НОВОШЕШМИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул. Советская, д.80,
с. Новошешминск,423190

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЯҢА ЧИШМӘ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ
Совет урамы, 80,
Яңа Чишмә авылы, 423190

тел.: (8-84348) 2-31-00, факс: (8-84348) 2-20-22, chishma@tatar.ru

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

2024 елның «16» маеннан № 143

Бюджет өлкәсе хезмәткәрләренә хезмәт өчен түләү буенча бердәм тариф челтәре кагылмый торган аерым бюджет өлкәсе оешмалары хезмәткәрләренең вазыйфаи окладларын арттыру һәм Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең «Яңа Чишмә муниципаль районының бюджет өлкәсе хезмәткәрләренә хезмәт өчен түләү буенча бердәм тариф челтәре кагылмый торган аерым бюджет өлкәсе оешмалары хезмәткәрләренең хезмәт өчен түләү шартлары турында» 2018 елның 03 маендагы 207 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында

Бюджет өлкәсе хезмәткәрләренә хезмәт хакы түләү буенча бердәм тариф челтәре кагылмый торган аерым оешмалар хезмәткәрләренең хезмәт хакын тәртипкә китерү һәм социаль гарантияләрне тәэмин итү максатларында Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитеты карар бирә:

1. 2024 елның 1 июленнән бюджет өлкәсе хезмәткәрләренә хезмәт хакы түләү буенча бердәм тариф челтәре кагылмый торган аерым оешмаларның җитәкчеләренең, белгечләренең һәм хезмәткәрләренең айлык вазыйфаи окладлары күләмнәрен Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Бюджет өлкәсендәге аерым оешмалар хезмәткәрләренең вазыйфаи окладлары күләмнәрен арттыру турында» 2024 елның 29 апрелендәге 287 номерлы карары билгеләнгән тәртип буенча арттырырга, Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитетының «Яңа Чишмә муниципаль районының бюджет өлкәсе хезмәткәрләренә хезмәт өчен түләү буенча бердәм

тариф челтәре кагылмый торган аерым бюджет өлкәсе оешмалары хезмәткәрләренең хезмәт өчен түләү шартлары турында» 2018 елның 03 маендагы 207 номерлы карарына (Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитетының 2018 елның 18 июлендәге 290 номерлы, 2020 елның 21 сентябрендәге 233 номерлы, 2021 елның 18 ноябрендәге 438 номерлы, 2022 елның 12 сентябрендәге 250 номерлы, 2022 елның 01 декабрендәге 351 номерлы карарлары белән кертелгән үзгәрешләр белән) үзгәрешләр кертергә.

2. Бюджет өлкәсенең хезмәт өчен түләү буенча бердәм тариф челтәре кагылмый торган аерым оешмалары җитәкчеләре, белгечләре һәм хезмәткәрләренең вазыйфаи окладлары күләмен исәплә өчен, әлеге карарның 1 пункты нигезендә, Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы бюджет өлкәсенең хезмәт өчен түләү буенча бердәм тариф челтәре кагылмый торган муниципаль берәмлекләрдәге бюджет өлкәсе аерым оешмасының структур бүлекчәсе җитәкчесенең секретаренең вазыйфаи окладының күләмен 1,05 мәртәбә индексацияләргә һәм аны 13 323 сум күләмендә билгеләргә.

3. Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитетының «Яңа Чишмә муниципаль районының хезмәт өчен түләү буенча бердәм тариф челтәре кагылмый торган бюджет өлкәсенең аерым оешмалары хезмәткәрләренең хезмәт хакын оештыру һәм түләү шартлары турында» 2018 елның 3 маендагы 207 номерлы карарына (Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитетының 2018 елның 18 июлендәге 290 номерлы, 2020 елның 21 сентябрендәге 233 номерлы, 2021 елның 08 ноябрендәге 438 номерлы, 2022 елның 12 сентябрендәге 250 номерлы, 2022 елның 01 декабрендәге 351 номерлы карарлары белән кертелгән үзгәрешләр белән) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

3 пункттагы 3 пунктчада «15 процент» сүзен «37 процент» сүзләренә алмаштырырга;

7 пункттагы 4 пунктчада «15 процент» сүзен «37 процент»сүзләренә алмаштырырга.

4. Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районының Финанс-бюджет палатасына әлеге карарны гамәлгә ашыруга бәйле чыгымнарны билгеләнгән тәртиптә финанслауны тәэмин итүне тәкъдим итәргә.

5. Әлеге карар 2024 елның 1 июленнән үз көченә керә дип билгеләргә.

6. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат - телекоммуникация челтәрендәге «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталы»нда http//pravo.tatarstan.ru, «Интернет» мәгълүмат - телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталында Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районының рәсми сайтында http//novosheshminsk.tatarstan.ru/ бастырып чыгарырга.

7. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең беренче урынбасарына (икътисад буенча) йөкләргә.

Җитәкче Р.Р. Фасахов